Исполнительный комитет
Большецильнинского сельского поселения
Дрожжановского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Зур Чынлы авыл җирлеге
Башкарма комитеты

422461, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с.Большая Цильна,
ул.Советская, 13 тел.(84375)38-6-16,факс 38-6-35 Bcel.Drz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 июнь 2020 ел № 15

Йорт хайваннарын урамда йөртү өчен урыннар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль Закон, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 ел, № 489-ФЗ Федераль закон, авыл җирлеге Уставы нигезендә, Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын урамда йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

-хуҗасы милкендә яки кулланышта булган җир кишәрлекләре;

- бордникларда һәм аларның хуҗалары күзәтүе астында кешеләр күпләп җыелмаган авыл җирлеге территориясендәге буш урыннар, торак сектор артында урнашкан урыннар:

1) Зур Чынлы авылының төньяк өлешендә М.Җәлил урамыннан 50 метр;

2) Зур Чынлы авылының урта өлешендә К.Маркс урамыннан 50 метр;

3) Зур Чынлы авылының көньчыгыш өлешендә Кыр урамыннан 50 метр ераклыкта;

4) Зур Чынлы авылының көньбатыш өлешендә Тукай урамыннан 50 метр ераклыкта;

2. Балалар һәм спорт мәйданчыкларында, парклар, скверлар, массакүләм ял итү урыннарында, балаларга белем бирү һәм дәвалау учреждениеләрендә, мәдәният объектларына якын территорияләрдә, кибетләрдә, хайваннар белән бергә бару өчен махсус объектлардан тыш, йорт хайваннарын ирекле йөртүне тыярга.

Әлеге пунктның гамәлдә булуы поводырь этләренә кагылмый.

3. Җирле үзидарә органы карары белән хайваннарны урамда йөртү өчен рөхсәт ителгән урыннардан читтә йөртүгә, юл куймаска.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Зур Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Ф.Җ.Фатхуллов